**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2019 ел, 17 октябрь №155

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының 2008 ел, 15 гыйнвар, 1/1 номерлы “Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законның 16.1 статьясына һәм нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Уставына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының 2008 ел, 15 гыйнвар, 1/1 номерлы карарына “Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, 4.1 статьясындагы 4.1 өлеше, Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 1 һәм 37 статьяларына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы карар итте:”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Уставында каралган тәртип буенча авыл җирлегенең максус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башлыгы –**
**Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы Рәисе Р. Х. Гыйльметдинова**